| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___28.02.2022___ Казан шәһәре №______31-ОД_____

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмә раслау хакында» 2020 елның 16 ноябрендәге 186-ОД санлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында бер төр нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 54 санлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмә раслау хакында» 2020 елның 16 ноябрендәге 186-ОД санлы боерыгына (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2021

елның 23 ноябрендәге 214-ОД санлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта» сүзләрен өстәргә.

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында законнарда билгеләнгән срокта дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Җыелма бүлеккә әлеге боерыкны әлеге боерыкны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Т.И.Саматовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр А.Ә. Кәримов